ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ИВАНОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН	ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИВАНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 27 октябре № 11

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Михайловка авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм файдалану буенча гражданнар җыены үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлегенең Михайловка авылында гражданнарның үзара салым акчасын кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 21 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2022елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Ивановка авыл җирлеге Михайловка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлар, тыл хезмәтчәннәре, күп балалы гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

I. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Үзәк урамы буенча (25нче йорттан һәйкәлгә кадәр)юлларга вак таш җәю;
- Михайловка авылында (Үзәк ур., Югары ур.) юлларны кардан чистарту

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Ивановка авылы, Үзәк урам, 27 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Ивановка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П.Бодряева